БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 02 2022 ел № 111

Татарстан Республикасында Россия хәрби-тарихи җәмгыяте региональ бүлекчәсенең җирле бүлекчәсен төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021елның 2 декабрендәге 03-54/15918 номерлы хатын үтәү йөзеннән һәм җәмәгатьчелек игътибарын тарихи-мәдәни мирас объектларына, патриотизм тәрбияләү һәм яшь буын тарафыннан илебезнең үткәненә сак караш тәрбияләү мәсьәләләренә җәлеп итү, «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы (алга таба – РХТҖ (РВИО)) эшчәнлеген популярлаштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасында Россия хәрби-тарихи җәмгыяте региональ бүлекчәсенең җирле бүлекчәсен төзергә.
2. «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгына Россия хәрби-тарихи җәмгыятен оештыру өчен җаваплы зат итеп Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча Балтач яшьләр формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры Ф. Ш. Гыйлемҗановны билгеләргә.
4. Илебезнең хәрби тарихын популярлаштыруга юнәлдерелгән хәрби-тарихи юнәлештәге иҗтимагый файдалы чаралар, хәрби-спорт уеннары, конкурслар һәм Россия хәрби-тарихи җәмгыяте проектларын үткәргәндә, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә мәгълүматны #РВИО, #РВИОвРТ хештеглары белән урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «18» 02
111 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1 статья. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Нигезләмә «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы уставы нигезендә (алга таба текст буенча – «Җәмгыять» ) эшләнгән һәм Җәмгыять әгъзаларына кабул итү һәм Җәмгыятьтә әгъза булуны туктату тәртибен, әгъзалык кертемнәрен (взносларын) түләү күләмен һәм тәртибен, физик затларны Җәмгыять әгъзаларына кабул итү турында гариза формасын, әгъза булу билетлары үрнәкләрен, юридик затны Җәмгыять әгъзаларына кабул итү турында Таныклык формасын билгели.

1.2. Җәмгыятьтә әгъза булу ирекле.

1.3. Җәмгыятьнең максатларына ирешү, аның бурычларын бергәләп хәл итү белән кызыксынучы, әгъзалык кертемнәрен түләүче 18 яшькә җиткән хокукый сәләтле физик затлар, шулай ук юридик затлар - иҗтимагый берләшмәләр Җәмгыять әгъзалары була ала.

1.4. Россия Федерациясендә законлы нигездә булган чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре яисә федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, җәмгыять әгъзалары була ала. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар җәмгыятьтә хокуклары һәм бурычлары булмыйча гына Җәмгыятьнең мактаулы әгъзалары булып сайлана ала.

1.5. Түбәндәгеләр Җәмгыять әгъзасы була алмый:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аларның Россия Федерациясендә булуларын (яшәүләрен) теләмәү турында карар кабул ителгән чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат;

2) "Җинаять юлы белән алынган акчаларны легальләштерүгә (юдыруга) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында" 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 пункты нигезендә исемлеккә кертелгән зат;

3) "Экстремизм эшчәнлегенә каршы тору турында" 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - "Экстремизм эшчәнлегенә каршы тору турында" Федераль закон) 10 статьясы нигезендә эшчәнлеге туктатылган иҗтимагый берләшмә;

4) законлы көченә кергән суд карары белән аның гамәлләрендә экстремизм эшчәнлеге билгеләре булуы ачыкланган зат;

5) суд карары буенча ирektән мәхрүм итү урыннарында булган зат.

1.6. Җәмгыять әгъзаларының исәбен территориясе чикләрендә әлеге җәмгыять әгъзасы - физик яки юридик зат теркәлгән региональ бүлекчәләр алып бара.

1.7. Җәмгыять әгъзаларының гомуми исәбен Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясе тәэмин итә.

1.8. Җәмгыять әгъзалары - физик һәм юридик затлар - бертигез хокукларга ия һәм аларга бертигез бурычлар йөкләнә.

## 2 статья. Җәмгыять әгъзаларына кабул итү.

2.1. Физик затлар җәмгыяте әгъзаларына кабул итү Җәмгыятьнең Үзәк советы, Җәмгыятьнең региональ бүлекчәләре Советлары тарафыннан шәхси гаризалар нигезендә башкарыла. Гаризалар кәгазь чыганакта Җәмгыятьнең Үзәк Советына, Җәмгыятьнең региональ бүлекчәләре Советларына, шулай ук http://rvio.histrf.ru сайты ресурслары аша электрон рәвештә бирелергә мөмкин.

2.2. Юридик затларны Җәмгыять әгъзаларына кабул итү, Җәмгыять әгъзаларына керергә ниятләгән тиешле юридик затның вәкаләтле җитәкче органы карарының күчермәсен кушып, шул исәптән http://rvio.histrf.ru сайты ресурслары аша электрон рәвештә бирелгән гариза нигезендә Җәмгыятьнең Үзәк Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җәмгыять әгъзаларына кабул итү турында гариза формасы әлеге Нигезләмәнең 1 нче һәм 2 нче кушымталарында билгеләнгән.

2.3. Җәмгыять әгъзаларына кабул итү турында карар Җәмгыятьнең Үзәк Советы яисә Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советы тарафыннан утырышта тиешенчә Җәмгыятьнең Үзәк Советы яки Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советы әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашу шарты белән, якын арадагы утырышларда утырышта катнашучылар саныннан күпчелек тавыш белән гади генә тавыш белән кабул ителә.

2.4. Җәмгыятьне оештыручылары, Җәмгыятьнең структур бүлекчәләрен оештыручылары – физик затлар, юридик затлар – иҗтимагый берләшмәләр, Җәмгыять (Җәмгыятьнең структур бүлекчәсе) барлыкка килгәннән соң, автомат рәвештә җәмгыятьнең әгъзалары булалар. Әлеге Җәмгыять әгъзалары турында хисап язмалары әлеге Нигезләмәнең 6 статьясы нигезендә Җәмгыять әгъзалары реестрына кертелә.

2.5. Җәмгыятьтә физик затның әгъза булуы әгъзалык билеты белән раслана. Әгъзалык билеты формасы әлеге Нигезләмәнең 3 нче , 5 нче кушымталарында билгеләнгән.

2.6. Юридик затның Җәмгыятьтә әгъза булуы әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында билгеләнгән Җәмгыять әгъзасына кабул итү турында таныклык белән раслана.

2.7. Юридик зат - Җәмгыять әгъзасы Җәмгыять органнары эшчәнлегендә вәкаләтле вәкилләре аша катнаша, аларның саны Җәмгыятьнең Үзәк советы, Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советы тарафыннан билгеләнә.

2.8. Җәмгыять әгъзалары әлеге Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасында билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә әгъзалык кертемнәрен түлиләр.

## 3 статья. Җәмгыятьтә әгъза булуны туктату.

3.1. Җәмгыятьтә әгъза булуны туктату нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

3.1.1. Физик затның Җәмгыять әгъзаларыннан ирекле чыгуы турында турында гаризасы.

3.1.2. Юридик затның вәкаләтле җитәкче органының тиешле карарының күчермәсен беркетеп, аның җәмгыять әгъзаларыннан ирекле чыгуы турында гаризасы.

3.1.3. Физик затның үлеме.

3.1.4. Юридик затның эшчәнлеген туктату (үзгәртеп кору, ябу яисә Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру юлы белән).

3.1.5. Билгеләнгән тәртиптә Җәмгыять әгъзасын – физик затны, хокукый сәләтсез дип тану.

3.2. Җәмгыять әгъзасын төшереп калдыру нигезләре булып түбәндәгелә тора:

3.2.1. Өч ай рәттән әгъзалык кертемнәрен түләмәү.

3.2.2. Җәмгыять Уставы таләпләрен яисә Җәмгыятьнең җитәкче органнары карарларын үтәмәү, шулай ук Җәмгыятьнең максатларына һәм бурычларына каршы килүче гамәлләр кылу (гамәл кылмау).

3.2.3. Җәмгыятьнең җитәкче органнарының ышанычы югалу.

3.2.4. Җәмгыятьнең бөтенлеген җимерү, Җәмгыять мөлкәтен законсыз тартып алу;

3.2.5. Җәмгыятьнең региональ һәм җирле бүлекчәләре үткәрә торган җыелышларда, утырышларда, башка чараларда катнашмау;

3.2.6. Җәмгыятьнең абруена тап төшерүче гамәлләр кылу;

3.2.7. Җәмгыять белән элемтә югалу.

3.3. Җәмгыятьтә әгъза булу Җәмгыятьнең Үзәк Советына яисә Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советына җәмгыять әгъзаларыннан ирекле чыгу турында гариза кергән көннән туктатыла. Башка очракларда Җәмгыятьтә әгъза булу Үзәк Совет яки Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советы тарафыннан җәмгыятьтә әгъза булуны туктату турында карар кабул ителгән көннән туктатыла.

3.4. Җәмгыятьнең Үзәк Советы, Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советы Җәмгыятьтә әгъза булуны туктату яисә Җәмгыятьнең Уставында каралган нигезләр буенча Җәмгыятьнең теләсә кайсы әгъзасына карата Җәмгыять әгъзаларыннан төшереп калдыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

3.5. Әгъза булуны туктату, Җәмгыять әгъзаларыннан төшереп калдыру турында карар Җәмгыятьнең Үзәк Советы яисә Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советы тарафыннан тавыш бирүдә Җәмгыятьнең Үзәк Советы яисә Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советы әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашкан очракта Җәмгыятьнең утырышта катнашкан әгъзаларының гомуми санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.6. Җәмгыятьтә әгъза булу туктатылган яки Җәмгыять әгъзаларыннан төшереп калдырылган очракта, Җәмгыятьтә әгъза булу турында таныклык Җәмгыятьнең башкарма дирекциясенә кире кайтарылырга тиеш.

3.7. Җәмгыять әгъзаларыннан үз теләге белән чыккан Җәмгыять әгъзасы Җәмгыять әгъзаларына кабат кабул ителергә мөмкин, әмма аннан чыкканнан соң бер елдан да иртәрәк түгел.

## 4 статья. Җәмгыять әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Җәмгыять әгъзалары хокуклы:

4.1.1. Җәмгыять эшләре белән идарә итүдә катнашырга, РФ Граждан кодексының 84 статьясындагы 2 пунктында каралган очрактан тыш;

4.1.2. әлеге Устав һәм гамәлдәге законнар нормалары белән каралган очракларда һәм тәртиптә Җәмгыять эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга һәм аның исәп-хисап (бухгалтерлык) һәм башка документлар белән танышырга;

4.1.3. граждан-хокукый нәтиҗәләргә китерә торган җәмгыять органнары карарларына законда каралган очракларда һәм тәртиптә шикаять бирергә;

4.1.4. Җәмгыять эшчәнлегендә катнашырга, Җәмгыятьнең җитәкче һәм контроль-ревизия органнарына сайлап алырга һәм сайланырга, әлеге Устав нигезендә Җәмгыятьнең җитәкче органнары эшчәнлеген контрольдә тотырга;

4.1.5. Җәмгыятьнең грант эшчәнлегендә башка катнашучылар белән уртак нигезләрдә Җәмгыять грантлары алырга;

4.1.6. Җәмгыять мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән документлар булганда, Җәмгыять, закон, башка хокукый акт яисә әлеге Устав нигезләмәләре нигезендә, аның исеменнән чыгыш ясарга вәкаләтле затлар исеменнән эш итеп, Җәмгыятькә китерелгән зыянны каплатуны таләп итәргә;

4.1.7. Җәмгыять мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән документлар булганда, Җәмгыятьнең вәкаләтле затлары тарафыннан үзләрендә булган вәкаләтләреннән читкә чыгып һәм Җәмгыять мәнфәгатьләренә зыян китереп кылган алыш-бирешләргә дәгъва белдерергә һәм аларның гамәлдә булмау нәтиҗәләрен куллануны, шулай ук Җәмгыятьнең әһәмиятсез сату-алу эшчәнлеге нәтиҗәләрен куллануны таләп итәргә.

4.1.8. Җәмгыятьнең тиешле эшчәнлегендә башка катнашучылар белән уртак нигезләрдә финанслау, финанслашу алырга.

4.1.9. Җәмгыять чараларын үткәргәндә Җәмгыятьнең символикасын (рәсми брендбук нигезендә) урнаштырырга.

4.1.10. Җәмгыять органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга.

4.1.11. Җәмгыять тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Җәмгыятьнең китапханә, архив һәм музей фондларыннан файдаланырга;

4.1.12. Җәмгыять басмаларында үзенең фәнни һәм башка хезмәтләрен бастырып чыгарырга.

4.1.13. Җәмгыятьтән ирекле рәвештә чыгарга;

4.1.14. Җәмгыять тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән түләүсез файдаланырга.

4.2. Җәмгыять әгъзалары бурычлы:

4.2.1. әлеге Уставның һәм Җәмгыятьнең эчке документлары нигезләмәләрен үтәргә;

4.2.2. Җәмгыять эшендә актив катнашырга;

4.2.3. Җәмгыятьнең җитәкче органнары үз компетенцияләре чикләрендә кабул иткән карарларын үтәргә;

4.2.4. Җәмгыять эшчәнлеге турында яшерен (конфиденциаль) мәгълүматны таратмаска;

4.2.5. алардан башка Җәмгыять үз эшчәнлеген Россия Федерациясе законнары нигезендә дәвам итә алмый торган карарлар кабул итүдә катнашырга, әгәр аларның катнашуы мондый карарлар кабул итү өчен кирәк булса;

4.2.6. күрә торып Җәмгыятькә зыян китерүгә, шулай ук Җәмгыять абруена тап төшерүгә юнәлтелгән гамәлләр кылмаска;

4.2.7. Җәмгыятьне төзү максатларына ирешүне кыенлаштыра яки аларга ирешүне мөмкин булмаслык итә торган гамәлләр (гамәл кылмау) башкармаска;

4.2.8. Җәмгыятьнең максатларын һәм бурычларын уңышлы хәл итүгә, аның абруен ныгытуга ярдәм итәргә;

4.2.9. күләме һәм түләү тәртибе Җәмгыять Съезды тарафыннан билгеләнә торган әгъзалык кертемнәрен түләргә, Җәмгыять мөлкәтен кирәкле күләмдә барлыкка китерүдә Россия Федерациясе Граждан кодексы, башка закон, әлеге Устав белән каралган тәртиптә, ысул белән һәм вакытларда катнашырга.

## 5 статья. Җәмгыятьнең мактаулы әгъзасы.

5.1. Җәмгыятьнең Үзәк Советы тәкъдиме буенча күренекле дәүләт, хәрби, сәяси һәм җәмәгать эшлеклеләре, шулай ук Россия дәүләтен үстерүгә һәм ныгытуга аерым өлеш керткән юридик затлар Җәмгыятьнең Мактаулы әгъзасы исеменә лаек булырга мөмкин.

5.2. Җәмгыятьнең Мактаулы әгъзасы исемен бирү турында карар Җәмгыять Рәисе тәкъдиме буенча Җәмгыятьнең Үзәк Советы Президиумы тарафыннан кабул ителә. Җәмгыятьнең Мактаулы әгъзасы статусы чикләнмәгән вакытка бирелә.

5.3. Җәмгыятьнең Мактаулы әгъзаларына билгеләнгән үрнәктәге әгъзалык билеты бирелә (5 нче кушымта).

5.4. Җәмгыятьнең Мактаулы әгъзалары Җәмгыять әгъзаларының барлык хокукларына һәм бурычларына ия.

5.5. Җәмгыятьнең Мактаулы әгъзасы Җәмгыятьнең барлык органнары утырышларында катнашырга хокуклы.

## 6 статья. Җәмгыять әгъзаларын исәпкә алу.

6.1. Җәмгыятьнең барлык әгъзаларының гомуми исәбе Җәмгыятьнең башкарма дирекциясе тарафыннан Җәмгыять әгъзалары реестрын файдаланып башкарыла.

6.2. Моннан тыш, Җәмгыять әгъзаларын исәпкә алуны аның территориясе чикләрендә әлеге Җәмгыять әгъзасы - физик яки юридик зат теркәлгән региональ бүлекчәләр гамәлгә ашыра.

6.3. Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе советы Җәмгыять әгъзаларына керүен һәм чыгуын раслый торган документларның төп нөсхәләрен саклауны тәэмин итәргә бурычлы. Җәмгыять әгъзаларына кабул итү турында гаризаның күчермәсе бирелгән әгъзалык билеты, җәмгыять әгъзаларына кабул итү турында таныклык хакында региональ бүлекчә советы тамгасы белән Башкарма дирекциягә җибәрелә.

6.4. Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясе Җәмгыять әгъзаларына кабул итү, Җәмгыятьнең Мактаулы әгъзасы исемен бирү белән бәйле документларны саклауны гамәлгә ашыра. Документларның төп нөсхәләре Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясенә саклауга тапшырыла.

6.5. Әлеге Нигезләмәнең 6.2, 6.4 пунктларында күрсәтелгән документларны юк итү Россия Федерациясендә архив эше турында гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6.6. Җәмгыятьнең региональ бүлекчәләре Советлары ай саен, хисаптан соң киләторган айның 5 (бишенче) числосына кадәр Җәмгыятьнең кабул ителгән/чыккан әгъзалары турында, шулай ук Җәмгыять әгъзалары реестрында булган мәгълүматлардагы үзгәрешләр турында мәгълүматны Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясенә төгәлләштерү һәм яңарту өчен җибәрәләр.

6.7. Җәмгыять әгъзалары реестры үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- Җәмгыять әгъзалары – физик затлар өчен: әгъзалык билетының номеры, фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, теркәлү урыны адресы һәм почта адресы, эш урыны, вазыйфасы, элемтә өчен телефон һәм электрон почта адресы, Җәмгыять әгъзаларына кабул ителү датасы, Җәмгыятьтә эшчәнлек юнәлеше, Җәмгыять әгъзаларыннан чыгу датасы һәм нигезе;

- Җәмгыять әгъзалары – юридик затлар өчен: әгъзалык турында таныклык номеры, юридик затның тулы исеме, юридик затның урнашу урыны адресы һәм почта адресы, төп Дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең шәхси номеры, Җәмгыять әгъзаларына кабул итү датасы, Җәмгыятьтәге эшчәнлек юнәлешләре, Җәмгыять әгъзаларыннан чыгу датасы һәм нигезе. Җәмгыять әгъзалары реестрына юридик зат органнары, юридик затның – җәмгыять әгъзасының вәкаләтле вәкилләре турында мәгълүмат кертелә (фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, элемтә өчен телефон һәм электрон почта адресы).

6.8. Өстәмә белешмәләр Җәмгыятьнең региональ бүлекчәләре һәм Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясе тарафыннан Җәмгыять әгъзалары реестрына кирәк булганда кертелә.

6.9. Җәмгыять әгъзалары реестрлары электрон һәм кәгазь чыганакта алып барылырга мөмкин.

6.10. Җәмгыять әгъзасы – физик зат номеры үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1 – нче билгеләр комбинациясе - региональ бүлекчә оештырылган регион коды; 2 – нче комбинация билгеләре - Җәмгыять әгъзасының региональ бүлекчәдә тәртип номерын билгели. Җәмгыять әгъзасыннан чыккан очракта, чыккан

Җәмгыять әгъзасының тәртип номеры Җәмгыятьнең башка әгъзасына тапшырылмый.

6.11. Җәмгыять әгъзасы – юридик зат номеры үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1 нче билгеләр комбинациясе – 100 (Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясенең код номеры); 2 нче билгеләр комбинациясе – Җәмгыяте әгъзасының - юридик затның Җәмгыять әгъзалары реестрында тәртип номеры. Җәмгыять әгъзасыннан чыккан очракта, чыккан Җәмгыять әгъзасының тәртип номеры Җәмгыятьнең башка әгъзасына тапшырылмый.

6.12. Җәмгыять әгъзасы бары тик бер региональ бүлекчәдә генә исәптә тора ала.

6.13. Фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, теркәлү урыны һәм/яки почта адресы, элемтә өчен телефон яки электрон почта адресы үзгәргәндә, физик зат - Җәмгыять әгъзасы бу хакта Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсенә язмача хәбәр итәргә тиеш. Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Җәмгыять әгъзасыннан хәбәр алынганнан соң 15 (унбиш) календарь көн эчендә һәм әлеге Нигезләмәнең 6.6 пункты белән билгеләнгән вакыт эчендә Региональ бүлекчәләр әгъзалары реестрына үзгәрешләр кертә, мәгълүматны Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясенә җибәрә.

6.14. Урнашу урыны адресы, почта адресы, элемтә өчен телефон яки электрон почта адресы үзгәргәндә, юридик затны - Җәмгыять әгъзасын үзгәртеп корганда, япканда, юридик зат тарафыннан аның вәкаләтле вәкилләре сыйфатында билдерелгән физик затлар белән юридик зат хокукый мөнәсәбәтләрне туктатканда, юридик зат мондый үзгәрешләр кертелгәннән соң 1 (бер) ай эчендә бу хакта язма рәвештә Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясенә хәбәр итә. Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясе Җәмгыять әгъзасыннан - юридик заттан хәбәр алынганнан соң 15 (унбиш) календарь көн эчендә Җәмгыять әгъзалары – юридик затлар реестрына үзгәрешләр кертә

6.15. Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсен бетергәндә, анда саклanuчы барлык документлар Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясенә тапшырыла.

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында 1 нче кушымта

Гаризаның теркәү номеры ______________
Җәмгыять әгъзаларына кабул итү көне
_________________
Әгъзалык билеты бирелде «___» ____________ 20___ ел
№ ____ __________

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасының
____________________________________________
буенча региональ бүлекчәсе Советы

(Россия Федерациясе субъекты)

__________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Туган көне _______________________, туган урыны
__________________________________
Шәхесне раслый торган документ
____________________________________________
№ _________ __________ Кем һәм кайчан биргән
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
Бүлекчә коды _________________________
Теркәлү адресы:________________
____________________________________________

## ГАРИЗА

Мине «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы (алга таба текст буенча - «Җәмгыять») әгъзаларына кабул итүегезне сорыйм.

Җәмгыять Уставы һәм Җәмгыять әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында нигезләмә белән таныштым:

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон нигезендә, минем тарафтан гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Үзем турында:

Белем _____________________________________________ . __________елны
(югары, урта махсус, урта) тәмамладым

____________________________________________________________
(уку йортының исеме)

белгечлек ______________________________________________
(белгечлек исеме)

________________________________________________гыйльми дәрәҗә (булганда) _____________ елда бирелде.

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте»нең мин актив катнашырга ниятләгән эшчәнлеге юнәлешләре (Х тамгасы белән билгеләргә):

| | | |
|---|---|---|
| 1 | фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, сугышлар тарихы һәм хәрби сәнгать | |
| 2 | белем бирү эшчәнлегенә ярдәм итү | |
| 3 | мәгърифәтчелек эшчәнлеге | |
| 4 | музей-күргәзмә эшчәнлеге | |
| 5 | архив-китапханә эшчәнлеге | |
| 6 | нәшрият һәм мәгълүмати-мәгърифәтчелек эшчәнлеге | |
| 7 | хәрби-тарихи һәм мемориаль һәйкәлләрне саклау, реставрацияләү, яңадан торгызу һәм булдыру | |
| 8 | хәрби-тарихи реконструкция | |
| 9 | фәнни-реставрация эшчәнлеге | |
| 10 | хәрби-археологик һәм эзләнү эшчәнлеге, артефактларны торгызу һәм реставрацияләү | |
| 11 | массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек | |
| 12 | халыкара эшчәнлек | |
| 13 | хәрби-спорт эшчәнлеге | |
| 14 | хәрби-музыкаль эшчәнлек | |
| 15 | хәрби-сәнгать эшчәнлеге, шул исәптән рәссам-баталистлар, маринистлар, театр һәм башка учреждениеләр белән эшләү | |
| 16 | иҗтимагый оешмалар, клублар, җәмгыятьләр, үзәкләр, фондлар белән хезмәттәшлек | |
| 17 | ветераннар оешмалары белән эшләү | |
| 18 | яшьләр белән хәрби-патриотик эш | |
| 19 | хәрби-тарихи туризм | |
| 20 | хәрби-спорт җәмгыятьләрен һәм оешмаларын үстерү | |

Почта адресы ________________________________________________________
________________________________ Элемтә телефоны:_______________________________
Электрон почта адресы: __________________________________________________________
Өстәмә мәгълүмат:
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

«___» __________________ 20___ ел ______________________ /________________________/

(Имза) (Фамилия, инициаллар)

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында 2 нче кушымта

Теркәлү номеры ______________________
Таныклык бирелде «___» ____________ 20___ ел
№ ___ _______________

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасының Үзәк Советына

_______________________________________________
(юридик затның исеме)
ОГРН______________ ИНН ______________
Юридик адрес ______________________
Почта адресы ______________________________
Элемтә телефоны __________________________
Электрон почта адресы ______________________

**ГАРИЗА**

_______________________________________________ «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» (алга таба текст буенча - «Җәмгыять») Гомумроссия иҗтимагый – дәүләт оешмасы әгъзаларына кабул итүегезне сорыйм.

Җәмгыятьтә вәкаләтле вәкилләр итеп түбәндәгеләр билгеләнә:

1. _______________________________________________.
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), оешмада вазыйфасы)

2. _______________________________________________.
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), оешмада вазыйфасы)

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте»нең актив катнашырга ниятләгән эшчәнлеге юнәлешләре (X тамгасы белән билгеләргә):

| | | |
|---|---|---|
| 1 | фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, сугышлар тарихы һәм хәрби сәнгать | |
| 2 | белем бирү эшчәнлегенә ярдәм итү | |
| 3 | мәгърифәтчелек эшчәнлеге | |
| 4 | музей-күргәзмә эшчәнлеге | |
| 5 | архив-китапханә эшчәнлеге | |
| 6 | нәшрият һәм мәгълүмати-мәгърифәтчелек эшчәнлеге | |
| 7 | хәрби-тарихи һәм мемориаль һәйкәлләрне саклау, реставрацияләү, яңадан торгызу һәм булдыру | |
| 8 | хәрби-тарихи реконструкция | |
| 9 | фәнни-реставрация эшчәнлеге | |
| 10 | хәрби-археологик һәм эзләнү эшчәнлеге, артефактларны торгызу һәм реставрацияләү | |
| 11 | массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек | |
| 12 | халыкара эшчәнлек | |
| 13 | хәрби-спорт эшчәнлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| 14 | хәрби-музыкаль эшчәнлек | |
| 15 | хәрби-сәнгать эшчәнлеге, шул исәптән рәссам-баталистлар, маринистлар, театр һәм башка учреждениеләр белән эшләү | |
| 16 | иҗтимагый оешмалар, клублар, җәмгыятьләр, үзәкләр, фондлар белән хезмәттәшлек | |
| 17 | ветераннар оешмалары белән эшләү | |
| 18 | яшьләр белән хәрби-патриотик эш | |
| 19 | хәрби-тарихи туризм | |
| 20 | хәрби-спорт җәмгыятьләрен һәм оешмаларын үстерү | |

Өстәмә мәгълүмат: ________________________________________________

Кушымта:

1. Җәмгыять әгъзаларына керергә ниятләгән юридик затның вәкаләтле җитәкче органы карары _______ биттә.

2. Оешма мөһере белән таныкланган Теркәлү турында таныклыкның, Салым исәбенә кую турында таныклыкның һәм Уставның күчермәләре _____ биттә.

Җитәкче __________________
(оешма атамасы)

«___» _______ 20___ ел ________________ /_____________/

М.У.

Искәрмә:

Җәмгыять Уставы һәм Җәмгыять әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында нигезләмә белән таныштым:

Җитәкче ________________________________________________________
(оешма атамасы)

«___» _______ 20___ ел ________________ /_____________/

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте»ндә ________________________________ вәкаләтле вәкиле
(оешманың исеме)

«___» _______ 20___ ел ________________ /_____________/


«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте»ндә ________________________________ вәкаләтле вәкиле
(оешманың исеме)

«___» _______ 20___ ел ________________ /_____________/

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында 3 нче кушымта

# Әгъзалык билеты формасы



«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында 4 нче кушымта

РОССИЙСКОЕ ВОЕННО-ИСТОРИЧЕСКОЕ ОБЩЕСТВО

Юридик затны «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» әгъзаларына кабул итү турында
ТАНЫКЛЫК
№ ___ _________

__________________________________________________ (ОГРН ______)
«РОССИЯ ХӘРБИ-ТАРИХИ ҖӘМГЫЯТЕ»
Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзасы булып торуы таныклана.

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте»
рәисе
М.У.
Мәскәү шәһәре «___» ____ 20___ ел _______________

«Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзаларын кабул итү һәм исәпкә алу тәртибе турында 5 нче кушымта

# Мактаулы әгъзаның әгъзалык билеты формасы



# «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасында әгъзалык кертемнәрен түләтү, исәпкә алу һәм тоту ТӘРТИБЕ

1. «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы (алга таба текст буенча - «Җәмгыять») Уставы нигезендә, Җәмгыять әгъзалары әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә даими рәвештә әгъзалык кертемнәре түләргә тиеш.

2. Җәмгыять составыннан чыгып киткән яисә төшереп калдырылган Җәмгыять әгъзалары әгъзалык кертемнәре сыйфатында түләнгән акчаларны кире кайтаруны, шулай ук Җәмгыятьтә әгъза булу белән бәйле башка чыгымнарны каплауны таләп итәргә хокуклы түгел.

3. Әгъзалык кертемнәрен түләү Җәмгыять әгъзалары тарафыннан һәр айның 15 (унбишенче) числосыннан да соңга калмыйча ай саен яисә әлеге Тәртипнең 6, 7 пунктында билгеләнгән еллык әгъзалык кертемен еллык хисап чорының беренче аеның 15 (унбишенче) числосыннан да соңга калмыйча түләү юлы белән башкарыла.

4. Җәмгыять әгъзаларына кабул ителгән зат,Җәмгыятьнең вәкаләтле органы тарафыннан җәмгыять әгъзаларына кабул итү турында карар кабул ителгәннән соң 10 (ун) календарь көн эчендә әлеге Тәртипнең 6, 7 пунктларында билгеләнгән күләмдә әгъзалык кертемнәрен түләргә тиеш.

5. Җәмгыять әгъзалары еллык әгъзалык кертемнәрен вакытында түләргә тиеш. Кертемнәрне түләү өчен беренче исәп-хисап чорының башы булып Җәмгыятьнең вәкаләтле органы тарафыннан затны Җәмгыять әгъзаларына кабул итү турында карар кабул итү датасы тора. Беренче исәп-хисап чорының тәмамлану вакыты булып Җәмгыять әгъзаларына кабул ителү елының 31 декабре тора. Алдагы барлык исәп-хисап чорлары тиешле елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр исәпләнә.

6. Җәмгыять әгъзалары - физик затлар өчен әгъзалык кертемнәренең күләме елына 1 200,00 (бер мең ике йөз) сум 00 тиен яки аена 100,00 (йөз) сум тәшкил итә.

7. Җәмгыять әгъзалары - юридик затлар өчен әгъзалык кертемнәренең күләме елына 12 000, 00 (унике мең) сум 00 тиен яки аена 1 200 (бер мең ике йөз) сум тәшкил итә.

8. Җәмгыятьнең Мактаулы әгъзалары әгъзалык кертемнәреннән азат ителә.

9. Әгъзалык кертемнәренең күләмен үзгәртү Җәмгыять Съезды карары буенча гамәлгә ашырыла.

10. Җәмгыять әгъзалары үз ихтыяры белән әгъзалык кертемнәрен әлеге Тәртипнең 6, 7 пунктларында билгеләнгәнгә караганда күбрәк күләмдә түли алалар.

11. Җәмгыять, тиешле үзгәрешләр үз көченә кергән көннән алып, 1 (бер) айдан да соңга калмыйча, Җәмгыятьнең рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, әгъзалык кертемнәренең күләмен үзгәртү турында хәбәр итә.

12. Физик затларның аерым категорияләренә әгъзалык кертемнәре түләү буенча ташламалар бирелергә мөмкин. **Ташламалар бирү турында карарлар Җәмгыять Съезды тарафыннан кабул ителә.**

13. Вакытында әгъзалык кертемнәрен түләмәгән Җәмгыять әгъзасына 10 (ун) календарь көн эчендә бурычларны түләү тәкъдиме белән Җәмгыять Уставын җитди бозу турында язмача хәбәр ителә.

**Өч айдан артык әгъзалык кертемнәрен түләү буенча бурычларны түләмәгән очракта, Җәмгыятьнең Үзәк Советы һәм/яки Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе Советы тарафыннан аны Җәмгыять әгъзаларыннан төшереп калдыру мәсьәләсе карала.**

14. Җәмгыять әгъзалары – физик затлар әгъзалык кертемнәрен Җәмгыятьнең исәп-хисап счетына, шул исәптән http://rvio.histrf.ru сайты аша, яисә Җәмгыять әгъзасы караган региональ бүлекчә Рәисенә түлиләр. Әгәр Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе юридик зат буларак теркәлсә - әгъзалык кертемнәрен Җәмгыять әгъзасы караган Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсенең исәп-хисап счетына яисә Җәмгыять әгъзасы караган региональ бүлекчә Рәисенә түләнергә тиеш. Җәмгыять әгъзалары - юридик затлар әгъзалык кертемнәрен Җәмгыятьнең исәп-хисап счетына түлиләр.

15. Физик затлар – Җәмгыять әгъзалары, әлеге 6 нчы кушымтаның 14 пункты нигезендә исәп-хисап счетына әгъзалык кертемнәрен түләгән очракта, түләү билгеләнешендә кертемнәр түләнә торган чорны һәм үзенең региоаналь бүлекчәсенең исемен күрсәтергә тиеш. Мәсәлән «00.00.20___ дан 00.00.20___ га кадәр әгъзалык кертемнәрен түләү (региональ бүлекчә _________________)».

Түләгәннән соң физик затлар үз региоаналь бүлекчәсенең Рәисенә түләү турында квитанция күчермәсен бирергә, ә Җәмгыятьнең рәсми сайты аша түләгән очракта Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясе хезмәткәрләре түләнгән әгъзалык кертемнәрен алганнан соң 15 (унбиш) эш көне дәвамында, Җәмгыятьнең тиешле региоаналь бүлекчәләре рәисләренә түләү турында мәгълүмат җибәрергә тиеш.

Региональ бүлекчә Рәисе, үз чиратында, түләү даталары буенча квитанцияләрнең күчермәләрен теркемли, барлык кирәкле мәгълүматларны әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналына кертә (6.1 нче кушымта - әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналы үрнәге), шуннан соң әлеге Тәртипнең 19 нчы пунктында яисә 20 нче пунктында күрсәтелгән хисапны квитанция күчермәләре белән бергә Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясенә җибәрә.

16. Әгъзалык кертемнәрен региональ бүлекчә Рәисенә түләгән очракта, Җәмгыять әгъзасы - физик зат, региональ бүлекчә Рәисенә кертемнәр нинди чор өчен түләнүе турында хәбәр итә. Региональ бүлекчә Рәисе, үз чиратында, әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналына (6.1 нче кушымта – әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналы үрнәге) тиешле язма кертә, шуннан соң Җәмгыять әгъзасы һәм региональ бүлекчә Рәисе журналның тиешле графаларына имза куя.

Акчаны әгъзалык кертемнәрен түләүгә алганнан соң, региональ бүлекчә Рәисе алынган акчаларны Җәмгыятьнең исәп-хисап счетына күчерә, ә Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсе юридик зат сыйфатында теркәлгән очракта - түләү билгеләнешендә «_________________ региональ бүлекчәсе реестры нигезендә әгъзалык кертемнәрен түләү» дип күрсәтеп, Җәмгыятьнең региональ бүлекчәсенең исәп-хисап счетына күчерә.

Әлеге Региональ бүлекчәдә исәптә торучы Җәмгыять әгъзалары өчен әгъзалык кертемнәрен күчергәннән соң, региональ бүлекчә Рәисе түләү датасыннан 5 (биш) эш көне дәвамында, ә региональ бүлекчә юридик зат сыйфатында теркәлгән очракта – әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә тиешле чор өчен әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналының күчермәләре (журнал битләренең күчермәләре региональ бүлекчә Рәисе имзасы белән раслана) белән бергә түләү турында квитанциянең (квитанцияләрнең) күчермәсен (күчермәләрен) Башкарма дирекциягә җибәрә.

17. Юридик затлар – Җәмгыять әгъзалары әгъзалык кертемнәрен түләгәндә, түләү билгеләнешендә кертемнәр түләнә торган чорны һәм әгъзалар - Юридик затлар реестры нигезендә Җәмгыять әгъзасы номерын күрсәтергә тиеш. Мәсәлән «00.00.20___ дан 00.00.20___ га кадәр әгъзалык кертемнәрен түләү (номер _____________)».

Түләгәннән соң Җәмгыять әгъзасы-юридик зат, түләү йөкләмәсенең күчермәсен Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясенә тапшырырга тиеш.

18. Әгъзалык кертемнәрен алуны оештыру һәм контрольдә тоту өчен региональ бүлекчә Рәисе, региональ бүлекчәләр Советлары, Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясе җаваплы.

19. Җәмгыятьнең региональ бүлекчәләре, әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр бер тапкыр Башкарма дирекциягә әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналы күчермәләре рәвешендә тиешле чор өчен түләнгән әгъзалык кертемнәре саны турында хисап тапшыралар (Журнал битләренең күчермәләре региональ бүлекчә Рәисе имзасы белән раслана).

20. Юридик зат сыйфатында теркәлгән Җәмгыятьнең региональ бүлекчәләре, хисап чорыннан соң килүче елның 15 февраленә кадәр, Башкарма дирекциягә тиешле чор өчен әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналы күчермәләре рәвешендә аларның исәп-хисап счетларына кергән әгъзалык кертемнәренең саны турында хисап (Журнал битләренең күчермәләре региональ бүлекчә Рәисе имзасы белән раслана) һәм югарыда күрсәтелгән әгъзалык кертемнәрен тоту турында хисап тапшыра.

21. Региональ бүлекчәләр тарафыннан бирелгән хисаплар нигезендә, Җәмгыятьнең Башкарма дирекциясе кертемнәр түләгән Җәмгыять әгъзаларының исәбен алып бара.

22. **Кергән әгъзалык кертемнәрен тоту тәртибе Җәмгыятьнең Үзәк Советы карары белән билгеләнә һәм Җәмгыять Рәисе тарафыннан раслана.**

23. **Әгъзалык кертемнәрен тоту буенча контроль Контроль-ревизия органнары тарафыннан башкарыла.**

6.1 нче кушымта Әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналы үрнәге

## _______________региональ бүлекчәсенең әгъзалык кертемнәрен исәпкә алу журналы.

| № т/б | Әгъзалык кертемнәрен түләү датасы | Җәмгыять әгъзасының ФИА (юридик затның исеме) | Вакыт (башлап) | Вакыт (кадәр) | Түләнгән сумма | Җәмгыять әгъзасының түләүдәге имзасы** | Алу турында РБ Рәисе имзасы ** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Әлеге журнал тәртип буенча тоташ нумерация белән алып барыла.
Журнал тегелергә тиеш, соңгы биттә региональ бүлекчә Рәисе имзасы, имзаның расшифровкасы торырга тиеш.
Әлеге журнал региональ бүлекчә Рәисендә катгый хисап документы буларак саклана һәм Җәмгыятьнең җитәкче, контроль-ревизия органнары, Җәмгыятьнең вазыйфаи затлары таләбе буенча бирелә.
** *Җәмгыять әгъзасы әгъзалык кертемен Җәмгыятьнең исәп-хисап счетына түләсә, тутырылмый.*